**КАРАР**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Чыбыклы авыл җирлеге Чыбыклы торак пунктында гражданнар җыены карары**

**15.11.2019** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Чыбыклы авыл җирлегенең Чыбыклы торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Көндезге бүлектә укучы студентлар, I группа инвалидлар, һәм ялгыз өлкәннәрдән кала, яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Чыбыклы авыл җирлегенең Чыбыклы авылында теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2020 елда үзара салымны 500 (биш йөз) сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итү өчен тотарга:

- Совет урамы буенча юлга вак таш һәм асфальт җәю, чокырларны ремонтлау;
- балалар мәйданчыкларын койма белән әйләндереп алу;
- зиратка капка сатып алу һәм урнаштыру;
- баганалар кую, Совет урамы буенча һәм күпердә светодиод яктырткычларны алыштыру;
- Вахитов урамына балалар мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру;
- чишмәгә элмә такта сатып алу һәм урнаштыру;
- һәйкәлне төзекләндерү (койманы һәм һәйкәлне буяу).

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Чыбыклы авыл җирлеге башлыгы** **И.Н. Гадершин**